**ГЛАВА НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

от «14» 2022 елның «14» мартыннан № 5

«2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисапны раслау хакында» проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2019 елның 24 октябрендәге 53-325 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмә»се, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә»се нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында яшәүчеләрнең «2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисапны раслау хакында» проекты турында фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. 2022 елның 18 мартында 17:00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының актлар залында (Совет урамы, 80нче йорт, Яңа Чишмә авылы, Яңа Чишмә районы, Татарстан Республикасы) «2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисабын раслау хакында» Татарстан Республикасы Яңа

Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

Ачык тыңлаулар тәртибе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябреннән14-105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы 2021елның 12 октябрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырылган нигезләмәгә туры китереп тормышка ашырыла.

2. «2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисапны раслау хакында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисабын раслау хакында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздыруны, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә һәм 2022 елның 23 мартына кадәр ачык тыңлаулар протоколын тапшырырга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә «2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисапны раслау хакында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектын, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм 2022 елның 25 мартына кадәр Яңа Чишмә муниципаль районы Советы утырышына кертергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Башлык В.М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2022 елның «14» мартыннан
5 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисабын раслау хакында» карар проектына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу
тәртибе

1. «2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисабын раслау хакында» карар проектына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Совет урамы, 80 йорт, каб. № 314 язма рәвештә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге җитәкчесенә тапшырыла.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырылган көннән алып эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 йорт, каб. № 314 шәхсән яки почта аша (конвертта«Бюджет турында фикер алышу» тамгасы белән).